КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 декабрь г.Казань № 1165

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә, IV бүлекнең 4.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.3.10 нчы һәм 4.3.11 нче пунктчалар өстәп, үзгәреш кертергә:

«4.3.10. Төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясе чикләрендә (дәвалау-савыктыру урыннарыннан һәм курортларыннан тыш) индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда планлаштырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителү (һәм/яки рөхсәт ителмәү) турында хәбәрнамәләр бирү.

4.3.11. Төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясе чикләрендә (дәвалау-савыктыру урыннарыннан һәм курортларыннан тыш) индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда җир кишәрлегендәге төзелгән яки реконструкция ясалган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамәләр бирү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин